КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 апрель г.Казань № 404

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен берләштерелгән лицензия буенча Татарстан Республикасы территориясендә федераль закон нигезендә бирелгән чикләрендә мондый файдалы казылмаларны развед-калау һәм чыгару буенча расланган техник проект нигезендә гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару тәртибен раслау турында» 2011 ел, 21 декабрь, 1042 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен яисә

берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен берләштерелгән лицензия буенча Татарстан Республикасы территориясендә федераль закон нигезендә бирелгән чикләрендә мондый файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару буенча расланган техник проект нигезендә гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару тәртибен раслау турында» 2011 ел, 21 декабрь, 1042 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2021 ел, 19 апрель, 255 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары участокларын федераль закон белән» сүзләрен «җир асты байлыклары участокларын «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары участокларын федераль закон белән» сүзләрен «җир асты байлыклары участокларын «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен берләштерелгән лицензия буенча Татарстан Республикасы территориясендә федераль закон нигезендә бирелгән чикләрендә мондый файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару буенча расланган техник проект нигезендә гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару тәртибендә:

исемендә «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары участокларын федераль закон белән» сүзләрен «җир асты байлыклары участокларын «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 191 статьясы, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 12 пункт нигезендә файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен

эшләү, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен берләштерелгән лицензия буенча Татарстан Республикасы территориясендә федераль закон нигезендә бирелгән чикләрендә мондый файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару буенча расланган техник проект нигезендә гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару тәртибен билгели.

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаның нумерацион башламында «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары участокларын федераль закон белән» сүзләрен «җир асты байлыклары участокларын «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның нумерацион башламында «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары участокларын федераль закон белән» сүзләрен «җир асты байлыклары участокларын «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы белән» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин